Муниципальное бюджетное дошкольное образовательное учреждение “Центр развития ребенка – детский сад № 36 “Волшебный дворец” г.Альметьевска РТ

ПРИНЯТО
на педагогическом совете
МБДОУ «ЦРР-д/ № 36 «Волшебный дворец»
«28» 08 2025г. протокол № 1

УТВЕРЖДАЮ
Заведующий МБДОУ
«ЦРР – д/с № 36 «Волшебный дворец»
Гудакова Т.Т.
Приказ от « » 09 2025г. № 44

# ДОПОЛНИТЕЛЬНАЯ ОБЩЕОБРАЗОВАТЕЛЬНАЯ ОБЩЕРАЗВИВАЮЩАЯ ПРОГРАММА ХУДОЖЕСТВЕННО-ЭСТЕТИЧЕСКОЙ НАПРАВЛЕННОСТИ
# “Нәсыйхәт”

для детей старшего дошкольного возраста (5-6 лет)
/срок реализации 1 год/

Авторы-составители:
Воспитатели высшей кв. категории
Усманова Р.М.
Мурдагулова В.Р.

г. Альметьевск, 2025 г.

**Нормативные основания для создания дополнительной общеобразовательной (общеразвивающей) программы**

- Федеральный закон от 29.12.2012 №273 ФЗ «Об образовании в Российской Федерации»,
- Концепция развития дополнительного образования до 2030 года (утверждена распоряжением Правительства РФ от 31.03.2022 №678-р),
- Постановление Главного государственного санитарного врача РФ от 28.09.2020 №28 «Об утверждении СП 2.4.3648-20 «Санитарно-эпидемиологические требования к организациям воспитания и обучения, отдыха и оздоровления детей и молодежи»,
- Письмо Министерства образования и науки РФ от 18.11.2015 №09-3242 «О направлении информации» (с Методическими рекомендациями по проектированию дополнительных общеобразовательных программ (включая разноуровневые программы),
- Приказ Министерства просвещения РФ от 27.07.2022 №629 «Об утверждении Порядка организации и осуществления образовательной деятельности по дополнительным общеобразовательным программам»

**Өстәмә гомуми белем (гомуми үсеш) программасын булдыру өчен норматив нигезләр**

- «Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 нчы декабрендәге №273 нче Федераль законы

- 2030 елга кадәр өстәмә белем үстеру концепциясе (Россия Федерациясе хөкүмәте 2022 елның 31 мартындагы 678-р боерыгы белән расланган)

- Россия Федерациясенең Баш дәүләт санитар табибының “Белем бирү, укыту, ял итү һәм сәламәтлекне яхшырту органнары өчен санитар һәм эпидемиологик таләпләр” турында 28.09.2020 елның 2.4.3648-20 карары

- Россия Федерациясенең Мәгариф һәм Фән Министрлыгының “Мәгълүмат юнәлешендә” (өстәмә гомуми белем бирү программаларын проектлау буенча методик тәкъдимнәр (күп дәрәҗәдәге программаларны да кертеп) 18.11.2015 елның №09-3242 нче хаты

- Россия Федерациясе Мәгариф Министрлыгының “Өстәмә гомуми белем бирү программаларында мәгариф эшчәнлеген оештыру һәм тормышка ашыру вакытын раслау турында” 27.07.2022 елның №629 нче боерыгы

## Программа эчтәлеге

Өстәмә гомуми белем (гомуми үсеш) программасының
мәгълүмат картасы....................................................4 бит
I бүлек........................................................................6 бит
1. Кереш өлеш...........................................................6 бит
2. Аңлатма язуы.........................................................7 бит
3. Программаның максаты........................................8 бит
4. Программаның бурычлары....................................8 бит
5. Программаның актуальлеге...................................8 бит
6. Программаның принциплары................................9 бит
7. Программаның яңалыгы.........................................10 бит
8. Программаның билгеләнеше.................................10 бит
9. Күрсәтмәлелек чаралары.........................................10 бит
10. Көтелгән нәтиҗә....................................................10 бит
11. Эш формалары......................................................10 бит
II бүлек..........................................................................11 бит
12. Түгәрәкнең тематик планы...................................11 бит
13. Түгәрәкнең комплекслы-тематик планы.............13 бит
III бүлек.........................................................................15 бит
14. Программаны тормышка ашыру өчен оештыру
һәм педагогик шартлар...............................................15 бит
IV бүлек.........................................................................16 бит
15. Программаның үзләштерү сыйфатын билгеләү....16 бит
16. Кулланылган әдәбият.............................................17 бит

**Информационная карта дополнительной общеобразовательной (общеразвивающей) программы**
**Өстәмә гомуми белем (гомуми үсеш) программасының мәгълүмат картасы**

| | | |
|---|---|---|
| | **Полное наименование программы Программаның тулы исеме** | “Нәсыйхәт” |
| 1 | **Направленность программы Программаның юнәлеше** | Художественно-эстетическая<br><br>Сәнгать-эстетик |
| 2 | **Сведения о разработчиках Төзүчеләр турында мәгълүмат**<br><br>ФИО, должность<br>ФИО, вазифа | Усманова Разиля Мирзагитовна, Мурдагулова Венера Ринатовна, воспитатели по обучению детей татарскому языку<br><br>Татар теленә өйрәтүче тәрбиячеләр |
| 3 | **Сведения о программе:** Программа турында мәгълүмат | |
| 4 | Срок реализации<br>Гамәлгә ашыру вакыты | 1 год<br>1 ел |
| 5 | Возраст обучающихся<br>Балаларның яше | 5-6 лет (старший дошкольный возраст)<br>5-6 яшь |
| 6 | Характеристика программы:<br>- тип программы<br>- вид программы<br>- принцип проектирования программы<br>Программаның характеристикасы(төре, принциплары) | Өстәмә белем бирү программасы<br>Гомуми үсеш<br>Бер дәрәҗәле |
| 7 | Цель программы<br>Программаның максаты | Халкыбызның әдәбияты, сәнгате, мәдәнияте, гореф-гадәтләре үрнәгендә әхлаклы, югары культуралы шәхесләр тәрбияләү. |
| 8 | Образовательные модули (в соответствии с уровнями сложности содержания и материала программы)<br>Белем бирү модульләре (эчтәлек һәм материалның авырлык дәрәҗәсенә туры килүе) | Башлангыч |

| | | |
|---|---|---|
| 9 | Формы и методы образовательной деятельности<br>Белем бирү эшчәнлегенең формалары, ысуллары | Әти – әниләр белән берлектә осталык дәресләре; әти-әниләрнең фикерләрен өйрәнү; кечкенәләр каршында чыгыш ясау; татар халык авыз иҗаты, матур әдәбият үрнәкләре белән танышу;  экскурсияләр, очрашулар; әңгәмә, фикер алышулар;<br>кул эше, рәсемләү; рәсемнәр, иллюстрацияләр, мультфильмнар карау; җырлы – биюле, сүзле, өстәл арты уеннары. |
| 10 | Формы мониторинга, результативности<br>Мониторингның формасы, нәтиҗәлелеге | Диагностик биремнәр һәм күнегүләр, индивидуаль-фронталь эшләү, күзәтү. |
| 11 | Результативность реализации программы<br>Программаны тормышка ашыру  нәтиҗәлелеге | Балаларның иҗади эшләре, әти-әниләр өчен йомгаклау шөгыле |
| 12 | Дата утверждения и последний корректировки программы<br>Программаны раслау һәм төзәтмәләр кертү көне | 2023 ел, төзәтмәләр кертү 2024 ел. |

# I БҮЛЕК

## 1.Кереш өлеш

*Алтыннан бәһале, оҗмах нигъмәтләреннән*
*кадерле булган нәрсә – тәрбияле баладыр.*
*Ата һәм ана өчен тәрбияле бала кебек*
*олуг байлык һич булмас.*
*Тәрбияле бала дөньяда җанга шатлык*
*һәм ахирәттә йөзгә аклык китерер.*
*Р. Фахретдин*

Балаларда әхлаклылык сыйфатлары тәрбияләү, аларны кешеләр белән аралашу кагыйдәләренә өйрәтү – безнең алда торган иң мөһим бурычларның берсе. Халкыбыз: “Алтыдагы – алтмышта”, - дип, балачакта өйрәнелгән гадәтләрнең олыгайгач та онытылмавына ишарә ясап әйтә. Асыл сыйфатлар балачакта канга сеңдерелә һәм гомерлек гадәткә әверелә. Кеше аларны никадәр иртәрәк үзләштерсә һәм көндәлек гамәленә кертсә, шулкадәр аңа яшәү максатчанрак, мәгънәлерәк тоела, җәмгыятьтә андый кешенең абруе күтәрелә, гаиләдә ихтирамы, ышанычы арта.

Без үз алдыбызга халык йолаларына, традицияләренә, иҗатына, гореф-гадәтләренә, сәнгатенә таянып балаларда туган телгә хөрмәт, халкыбызга карата гүзәл әхлакый сыйфатлар тәрбияләү, милли фольклор әсәрләре аша, балаларның дөрес әдәби телдә сөйләшүләренә ирешү максаты куябыз.

Халыкның һәрьяклап үскән шәхес тәрбияләргә омтылышын чагылдырган һәм шуңа ирешү юлында туган традицияләре бар. Гореф-гадәт, йолалар тормышны бер тәртипкә салу, аның аеруча мөһим булган бер вакыйгаларын мәгънәле, төпле, дөрес итеп кичерү, һәр нәрсәнең урынлы булуын аңлата. Кешегә шатлыклы һәм кайгылы мизгелләрдә югалып калмаска өйрәтә, ярдәм итә. Гасырлар аша буыннан буынга килгән бу кануннарның тирән тамырлары тәрбиягә барып тоташа.

Кешенең гомере беренче чиратта гаиләдә үтә. Шуңа күрә дә гаилә тормышындагы вакыйгалар белән бәйле йолалар безнең эшебезнең төп эчтәлеген билгели дә инде. Гаилә бәйрәмнәре уздыру кебек чараларның тәрбияви йогынтысы – бәяләп бетергесез.

Безнең төп эшебез – тәрбия һәм белем бирү. Бу урында үзе дә мөгаллим булган Ризаэддин Фәхретдиннең “белем бирүнең нигезе – тәрбия... Тәрбиясе булмаган җирдә... гүзәл кеше дә җитешмәс” дигән искиткеч акыллы сүзләрен китерми мөмкин түгел. Вакытында тиешле тәрбия бирмибез икән, бүгенге яшь буын безнең булачак оныкларыбызга нинди тәрбия бирер соң?

Барыбызга да уңышлар телибез!

## 2.Аңлатма язуы

Сезнең игьтибарыгызга балалар бакчасында 5-6 яшьлек балалар белән әхлак тәрбиясенә юнәлдерелгән түгәрәк эшчәнлеген алып бару өчен төзелгән программа: аңлатма язуы, методик тәкъдимнәр, еллык комплекслы - тематик план һәм түгәрәк эшчәнлегенең эшкәртмәләре бирелә. Бу программа туган телебезгә хөрмәт, балаларда әхлакый сыйфатлар, татар халык авыз иҗатына һәм матур әдәбияткә мәхәббәт тәрбияләү максатын куя.

Программа “Балалар бакчасында тәрбия һәм белем бирү программасы” (Казан, “ Хәтер”, 2000) таләпләренә туры китереп иҗат ителде. Барлык тәкъдим ителгән материал үстерешле белем бирү һәм дидактик принципларга нигезләнеп язылды. Балаларның яшь үзенчәлекләре, индивидуаль сәләтләре, биремне башкару өчен көче җитү мөмкинлекләре исәпкә алынды.

Баланың мәктәпкәчә яшьтәге чоры – тирә – юньне йотлыгып өйрәнү, күп кичерешләрне үзенә туплау, кеше шәхесе формалашуда иң мөһим чор. Соңгы елларда тормышыбызда, яшәешебездә бара торган үзгәрешләрнең берсе – туган телгә, халыкның милли мәдәниятенә, рухи дөньясына игътибары көчәю. Бу исә балага туган көненнән башлап ана телендә тәрбия бирә башлауны, балалар бакчаларында максатлы рәвештә сабыйларны үз туган теленә өйрәтүнең иң актуаль мәсьәләләр рәтенә куйды. Ана теле – тою, сизү, йөрәк теле, рухи тамыр. Рухи тамырдан акыл, фикер эшчәнлегенә, белем һәм күнекмәләр туплауга, кешеләрне, дөньяны танып белүгә юл кыскарак. Без, тәрбиячеләрнең бурычлары: халык йолаларына, традицияләренә, иҗатына, гореф-гадәтләренә, сәнгатенә таянып балаларда туган телгә хөрмәт, халкыбызга карата гүзәл әхлакый сыйфатлар тәрбияләү, милли фольклор әсәрләре аша, балаларның дөрес әдәби телдә сөйләшүләренә ирешү. Балаларыбызда халкыбызга хас милли үзенчәлекләрне: кунакчыллык, сабырлык, шаянлык тәрбияләү.

Түгәрәк эшчәнлеге уңышлы һәм нәтиҗәле узсын өчен:
-тиешле педагогик шартлар тудыру,
- өйрәтү эшчәнлеген яңарту,
-нәтиҗәле алымнардан файдалану,
-түгәрәк эшчәнлеген максатка ярашлы рәвештә алыштырып тору,
- педагогның балаларны яратып, күңел биреп, иҗади эшләве кирәк.

Тәкъдим ителгән материал балаларны олы, катлаулы, гаять кызыклы дөньяга алып керүдә һәм әхлакый сыйфатларны үзләштерүдә файдалы ярдәмлек булыр дип ышанабыз.

## 3. Программаның максаты

Бала шәхесенең барлык эчке табигый көчләрен хәрәкәткә китерү, яңа җәмгыять шартларында әхлакый шәхес буларак тәрбияләү, балалар әдәбиятының иң матур үрнәкләре, татар халык авыз иҗатының төрле формалары белән таныштыру, халкыбызның әдәбияты, сәнгате, мәдәнияте, гореф-гадәтләре үрнәгендә әхлаклы, югары культуралы шәхесләр тәрбияләү.

## 4. Программаның бурычлары

- татар халкының тарихы, үткәне һәм бүгенгесе белән кызыксыну, горурлык хисләре уяту;
- татар халкының тормыш-көнкүрешендәге үзенчәлекләре, милли киемнәре, матур йолалары һәм бәйрәмнәре белән таныштыруны дәвам итү;
- туган телебезне ярату, зурлау, аны саклау хисләре тәрбияләү;
- Р.Фәхретдин хезмәтләре аша яшь буынның әхлакый сыйфатларын үстерү.

## 5. Программаның актуальлеге

Балаларга әхлакый тәрбия бирү — кешелек дөньясы алдында торган иң мөһим проблемаларның берсе. Кешенең әхлагы булмаса, ул үзе дә, аның тирә - ягындагылары да тәрбиясез була. Әхлак тәрбиясе иң башта гаиләдән башлана. Балаларның, үзара аралашулары һәммәбезне уйланырга, эзләнергә мәҗбүр итә. Шушы максат безне, балалар бакчасында эшләүче тәрбиячеләрне, халык педагогикасына мөрәҗәгать итәргә этәрә. Халык педагогикасы – фәнни педагогиканың нигезе. Анда борынгы заманнардан ук халык акылы, аның зирәк фикерләре, киңәшләре тупланган. Аларны һич тә югалтырга ярамый. Халыкның үзенә генә хас булган тарихи үсешен, аның психологиясен чагылдырган, балаларга һәм яшьләргә белем һәм тәрбия бирү ысуллары, чаралары турындагы карашлар, буыннан-буынга күчеп үсәргә, камилләшергә тиеш. Традицияләрне, гореф-гадәтләрне кире кайтару гына түгел, аларны заманчалаштыру, яңарту, гомумкешелек кыйммәтләре юнәлешендә үстерү дә мөһим эш.

## 6. Программаның принциплары

I принцип -гаилә  тәрбиясе һәм милли мохит булдыру.
Тәрбия милли булса гына  тиешле нәтиҗә бирә. Ә тәрбиянең нигезендә, әлбәттә, аралашу чарасы буларак, туган тел ята. Милли үзаң формалаштыруда туган телнең әһәмияте әйтеп бетергесез зур. Чөнки тел – халык байлыгы ул. Милләтне милләт итеп санарга хокук биргән бердәнбер шарт - ул тел мәсьәләсе. Милли үзаң үсешенең нигезе, нәкъ менә ана теле икәнлеге күптәннән расланган. Димәк, баланың үз ана телен үзләштерүе һәм аны актив куллануы, шул телдә тәрбия һәм белем алуы аның һәряклы үсеше өчен уңай шарт булып тора. Милли мохитнең икенче яссылыгы-баланы чолгап алган тирә-юньнең милли эчтәлектә булуы. Чөнки баланың эчке дөньясы, уй—фикерләре, омтылыш-хыяллары, яшәү һәм хәрәкәт рәвеше билгеле бер социаль тирәлек кысаларында формалаша. Ә шәхеснең тойгылары чын мәгънәсендә милли булсын өчен, бу тирәлек тә милли булырга тиеш.

II принцип - балаларда милләтебез белән горурлану хисе тәрбияләү.
Бу принципның нигезендә балаларны татар халкының милли сыйфатлары белән таныштыру ята. Аларның берсе- мөстәкыйллек. Мөстәкыйллекне сакларга тырышу аларны утка-суга да керткән, үзләренә хас һөнәр-кәсеп кешеләренә дә әверелдергән. Татарның башка халык белән аралаша белү сыйфаты бүгенге көндә дә яхшы чагылыш таба. Ул гомуми һәм шәхси мәсәләләрне тыныч ысул, аңлату юлы белән хәл итүне хуп күрә. Уңганлык, эшчәнлек сыйфатына килгәндә, халыкның бай һәм мул тормышта яшәгәнлеге моны исбат итеп тора. Батырлык - милләтебезнең горурланырлык сыйфаты. Татар беркайчан да үзе яшәгән Ватанга хыянәт итмәгән. Татарның *кунакчыллык* сыйфаты  зур сынаулар аша үткән. Элек-электән татарның йорты юлчыларга, адашып йөрүчеләргә, ярдәмгә мохтаҗларга ачык булган. Милләтебезнең һәммә халыкта ихтирам тудыра торган уңай сыйфаты-*чисталык, пөхтәлек.*

III принцип - татар халкының тарихы, мәдәнияте, халык педагогикасы чаралары белән таныштыру.
Бу  эш түбәндәге юнәлешләрдә алып барыла.
-Балаларда туган җиренә, үзенең нәселенә, атаклы кешеләренә ихтирам һәм мәхәббәт тәрбияләү.
-Татар халкының  мәдәнияте, гореф-гадәтләре, йола-бәйрәмнәре, халык уеннары белән таныштыру.
-Милли мәдәниятне дөнья халыклары мәдәнияте белән бәйләнештә өйрәнү. Бу бурычларны үтәүдә матур әдәбият, сәнгать төрләре ярдәмгә килә.

## 7. Программаның яңалыгы

Мәктәпкәчә белем бирү оешмалары алдында торган төп бурыч – мәктәпкәчә яшьтәге балаларның җәмгыятьнең тулы хокуклы әгъзалары булып җитешүе (социальләшүе), рухи-әхлакый үсеше, иҗади сәләтләренең камилләшүе өчен мөмкинлек тудыра торган шартлар, ягъни баланың һәрьяклы үсешен тәэмин итә торган белем бирү тирәлеге булдыру. Өстәмә белем бирү түгәрәгендә төп белем бирү эшчәнлегендә алган белем һәм күнекмәләр ныгытыла, киңәйтелә, гамәли кулланылышка кертелә.

## 8. Программаның билгеләнеше

5-6 яшьлек балалар белән “Нәсыйхәт” түгәрәге айга 4 тапкыр, атнага 1 мәртәбә көннең икенче яртысында уза. Шөгыльнең озынлыгы – 25 минут.

Түбәндәге принципларга таянып эшләү мәҗбүри:

- педагогның әзерлеге;
- бай эчтәлекле, темаларның һәм методик алымнарның төрлелеге;
- педагогик процессны оештыруның бөтен формаларын куллану;
- барлык баланың максималь актив катнашуы;
- иптәшләре һәм педагоглар белән хезмәттәшлек.

## 9. Күрсәтмәлелек чаралары

Риза Фахретдин тормышы, иҗаты белән бәйле видеофильмнар циклы, аның хезмәтләре, уенчыклар, иллюстрацияләр, рәсемнәр, өстәл арты уеннары, курчак театрының төрле төрләре, слайдлар, мультфильм җыентыклары, музыкаль бизәлеш өчен дисклар, экран, ноутбук.

## 10. Көтелгән нәтиҗә

Программаны тормышка ашыру барышында Р.Фәхретдин хезмәтләре аша яшь буынның әхлакый сыйфатлары үстерелә, балалар һәм ата-аналар бер-берсе белән аралашырга, төрле мәгълүмат белән эшләргә өйрәнә, туган тел, туган як, татар халкы, мәдәнияты, традицияләре турында күбрәк мәгълүмат туплана.

## 11. Эш формалары

- әти – әниләр белән берлектә осталык дәресләре;
- әти – әниләрнең фикерләрен өйрәнү;
- кечкенәләр каршында чыгыш ясау;
- татар халык авыз иҗаты, матур әдәбият үрнәкләре белән танышу;
- экскурсияләр, очрашулар;
- әңгәмә, фикер алышулар;
- кул эше, рәсемләү;
- рәсемнәр, иллюстрацияләр, мультфильмнар карау;
- җырлы – биюле, сүзле, өстәл арты уеннары.

# II БҮЛЕК
# 12.Түгәрәкнең тематик планы

| № | Ай исеме | Тема | Сәгать саны |
|---|---|---|---|
| 1. | Сентябрь | **“Тәрбияле бала”**<br>1 атна. “Әдәплелек нәрсә ул?”<br>2 атна. “Яхшы гадәтләр. Нәрсә ул яхшы, нәрсә ул начар?”<br>3 атна. “Тату гаилә”<br>4 атна. “Бөек галим – Р.Фәхретдин”. | 4 сәгать |
| 2. | Октябрь | **“Матурлык дәресләре”**<br>1 атна. “Мин ничек киенәм”<br>2 атна. “Китап – белем чишмәсе”<br>3 атна. “Без, без, без идек...”<br>4 атна. “Үзеңне тота белү матурлыгы” | 4 сәгать |
| 3. | Ноябрь | **“Сөмбеләгә – кунакка!”**<br>1 атна. “Сөмбеләне кем белә?” (онлайн рәсем дәресе)<br>2 атна. “Кояшлы табын”<br>3 атна. Сөйләм әдәбе: “Тылсымлы сүзләр”<br>4 атна. “Бергәләп басыйк әле, түгәрәк ясыйк әле!” | 4 сәгать |
| 4. | Декабрь | **“Барыбызга бер шатлык, бик кызык уен таптык!”**<br>1 атна.“Халык әкиятләре үзе бер кызык дөнья!”<br>2 атна. “Әбиемнең серле сандыгы”<br>3 атна. Минем яраткан әкият героем. (тозлы камырдан кул эше)<br>4 атна. “Тыңлагыз! Әкият сөйлим!” (кечкенәләр төркеме балалары өчен әкият күрсәтү) | 4 сәгать<br><br>4 сәгать |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 5. | Гыйнвар | **“Бергәләп басыйк әле, түгәрәк ясыйк әле!”**<br>1 атна. “Исемең матур – кемнәр куйган”<br>2 атна. “Затлы җепләр”.<br>3 атна. “Табышмак әйтәм, җавабын тап”.<br>4 атна. Татар халык түгәрәк уеннары | 4 сәгать |
| 6. | Февраль | **“Ярат туган телеңне”**<br>1 атна. “Мин бит татар баласы”<br>2 атна. “Иң татлы тел – туган тел, әнкәм сөйләп торган тел”<br>3 атна. “Туган ил, туган йорт”<br>4 атна. “Батыр егет – ил күрке” | 4 сәгать |
| 7. | Март | **“Иң кадерле кешебез”**<br>1 атна. “Әни кирәк”<br>2 атна. “Җырлыйм әнием турында”<br>3 атна. Әбием күчтәнәчләре<br>4 атна. Халкым йолалары. Бәйрәмнәр | 4 сәгать |
| 8. | Апрель | **“Тукайның экияти иленә күңелле сәяхәт”**<br>1 атна. Татар теле – минем туган телем!”<br>2 атна. Мультфильмнар карау.<br>3 атна. “Бала белән күбәләк”, “Кызыклы шәкерт” сәхнәләштереп уйнау.<br>4 атна. Осталык дәресе | 4 сәгать |
| 9. | Май | **“Кешене матурлый торган сыйфатлар”**<br>1 атна. “Тел. Сүз. Әдәп”<br>2 атна. “Мин кунакка барам”<br>3 атна. “Йөзек кашы”<br>4 атна. “Мин – тәрбияле бала!” | |

# 13. Түгәрәкнең комплекслы-тематик планы

| Вакыты | Тема | Максат |
|---|---|---|
| **Сентябрь**<br>1 атна | **“Тәрбияле бала”**<br>“Әдәплелек нәрсә ул?” | Өйдә, бакчада, урамда үз-үзеңне әдәпле тоту кагыйдәләрен өйрәнү. |
| 2 атна | “Яхшы гадәтләр. Нәрсә ул яхшы, нәрсә ул начар?” | Үз-үзеңне һәркайда тәртипле, дөрес тоту кагыйдәләрен белү, аларны үтәү. Ярамый, мөмкин сүзләренең мәгънәсен аңлау. |
| 3 атна | “Тату гаилә” | Гаиләнең татулыгы нәрсәгә бәйле икәнен аңлату: бер-береңә игътибарлы булу, ярдәмләшү һәм хөрмәтләү. |
| 4 атна | “Бөек галим – Р.Фәхретдин” | Яшь буынны тәрбияләүдә Р.Фәхреддин хезмәтләрен куллануны камилләштерү. |
| **Октябрь**<br>1 атна | **“Матурлык дәресләре”**<br>“Мин ничек киенәм” | Киенү әдәбен өйрәнүне дәвам итү. Үзеңнең тышкы кыяфәтеңне тәртипкә китерә белергә күнектерү. |
| 2 атна | “Китап – белем чишмәсе” | Китаплар белән кызыксыну, аларга сакчыл караш тәрбияләү, тел байлыкларын арттыру |
| 3 атна | “Без, без, без идек...” | Халык педагогикасы аша балаларда күңел күтәренкелеге, шатлык хисләре тәрбияләү. |
| 4 атна | “Үзеңне тота белү матурлыгы” | Тәрбиялелек – яшәү өчен кирәк булган иң гүзәл сыйфатларның берсе икәнлегенә төшендерү. |
| **Ноябрь**<br>1 атна | **“Сөмбеләгә – кунакка!”**<br>“Сөмбеләне кем белә?” (онлайн рәсем дәресе) | Милли бәйрәмнәребез белән таныштыруны дәвам итү, балаларга бәйрәм кәефе бүләк итү. |
| 2 атна | “Кояшлы табын” | Табын янында үзеңне культуралы тоту күнекмәләрен ныгыту |
| 3 атна | Сөйләм әдәбе: “Тылсымлы сүзләр” | Ягымлы сүзләрне куллана белергә, үз-үзеңне матур тотарга өйрәтү. |
| 4 атна | “Бергәләп басыйк әле, түгәрәк ясыйк әле!” | Балаларны фольклор әсәрләре белән кызыксындыру, аларның кабул итү сәләтләрен, хәтерләрен, уңай эмоцияләрен үстерү. |
| **Декабрь**<br>1 атна | **“Барыбызга бер шатлык, бик кызык уен таптык!”**<br>“Халык әкиятләре үзе бер кызык дөнья!” | Әкиятләр аша әхлакый сыйфатлар тәрбияләү. |
| 2 атна | “Әбиемнең серле сандыгы” | Милли киемнәрнең исемнәрен, бизәлешләрен сөйләмдә дөрес әйтүне активлаштыру, матурлыкка омтылу. |

| | | |
|---|---|---|
| 3 атна | Минем яраткан әкият героем. (тозлы камырдан кул эше) | Әкиятләр аша дустыңа, иң якын кешеңә карата мәрхәмәтлелек хисләре уяту. |
| 4 атна | “Тыңлагыз! Әкият сөйлим!” (кечкенәләр төркеме балалары өчен әкият күрсәтү) | Әкиятләрне анализлау процессында балаларда фикер йөртү һәм бәяли белү күнекмәләре формалаштыру. |
| **Январь** 1 атна | **“Бергәләп басыйк әле, түгәрәк ясыйк әле!”** “Исемең матур – кемнәр куйган” | Һәр исемнең аерым бер мәгънә белдерүе турында төшенчә бирү. |
| 2 атна | “Затлы җепләр” | Иҗади мөстәкыйльлек, нәфасәти зәвык тәрбияләү. |
| 3 атна | “Табышмак әйтәм, җавабын тап” | Балаларның уйлау, фикерләү сәләтләрен үстерү. Аларда тапкырлык, зирәклек, күзәтүчәнлек тәрбияләү |
| 4 атна | Татар халык түгәрәк уеннары | Халкыбыз уеннары белән таныштыруны дәвам итү, уеннар ярдәмендә балаларның күңелен күтәрү. |
| **Февраль** 1 атна | **“Ярат туган телеңне”** “Мин бит татар баласы” | Үзеңнең милләтең белән горурлану хисләре тәрбияләү. |
| 2 атна | “Иң татлы тел – туган тел, әнкәм сөйләп торган тел” | Туган телебезне ярату хисе тәрбияләү, туган телдә сөйләшәсе килү теләген үстерү. |
| 3 атна | “Туган ил, туган йорт” | Тугн ил, туган йортны ярату, аның белән горурлану хисләре, шәһәребезне матуррак итүдә катнашу теләге тәрбияләү. |
| 4 атна | “Батыр егет – ил күрке” | Кыю, батыр булу теләге уяту, куркаклыкка тискәре мөнәсәбәт тәрбияләү. |
| **Март** 1 атна | **“Иң кадерле кешебез”** “Әни кирәк” | Сабыйларыбыз күңелендә иң кадерле, изге кешеләребезгә ярату һәм хөрмәт хисләре тәрбияләү. |
| 2 атна | “Җырлыйм әнием турында” | Шигърият аша әниләргә мәхәббәт тәрбияләү, сәнгатьле сөйләм телләрен үстерү |
| 3 атна | Әбием кучтәнәчләре | Балаларның өлкәннәр хезмәте белән кызыксынуларын үстерү, өлкәннәр хезмәтенә хөрмәт тәрбияләү |
| 4 атна | Халкым йолалары. Бәйрәмнәр | Балаларны татар халкының милли бәйрәмнәре белән таныштыру. Бердәмлек, дуслык хисләре, халкыбыз йолаларына хөрмәт тәрбияләү. |

| | | |
|---|---|---|
| **Апрель**<br>1 атна | **“Тукайның әкияти иленә күңелле сәяхәт”**<br>“ Татар теле – минем туган телем!” | Туган телгә мәхәббәт тәрбияләү, аның белән кызыксыну хисләре уяту. |
| 2 атна | Мультфильмнар карау. | Мультфильмнарны туган телдә аңлап карауларына ирешү. |
| 3 атна | “Бала белән күбәләк”, “Кызыклы шәкерт” сәхнәләштереп уйнау | Габдулла Тукайның күпкырлы иҗатына мәхәббәт тәрбияләү. |
| 4 атна | Осталык дәресе | Кул эшләрендә милли бизәкләрне куллану. |
| **Май**<br>1 атна | **“Кешене матурлый торган сыйфатлар”**<br>“Тел. Сүз. Әдәп” | Тел, сүз, әдәп турында мәкальләр, әйтемнәр белән таныштыру, аларның әһәмиятен аңлату. |
| 2 атна | “Мин кунакка барам” | Балаларны кунакчыл булырга, кунакларга хөрмәт күрсәтә белергә өйрәтү. Халкыбызның күркәм гореф-гадәтләре турында сөйләү. |
| 3 атна | “Йөзек кашы” | Балаларда халкыбызның матур сыйфатларын тәрбияләү. |
| 4 атна | “Мин – тәрбияле бала!” | Күренекле мәгърифәтче Р.Фәхретдин мирасын гаиләдә һәм балалар бакчасында киң пропагандалау. |

## III БҮЛЕК
## 14. Программаны тормышка ашыру өчен оештыру һәм педагогик шартлар

1.Ноубук, проектор, экран, музыкаль үзәк, дисклар, аудио-видео язмалар, презентацияләр, магнит такта;
2.Методик ярдәмлекләр, әдәби китаплар, иллюстрацияләр, открыткалар, күрсәтмә һәм таратма рәсемнәр;
3.Риза Фахретдин хезмәтләре тупланган кечкенә китапханә, видеофильмнар циклы;
4. Модуль «Кафе Тәмле», модульле уен “Тылсымлы тартма”, “Татарча домино” уены, дидактик һәм өстәл уеннары,;
5. Театр төрләре өчен атрибутлар;
6. Практик рәсемләү һәм кул эшләре дәресләре өчен материал;
7. Төрле костюмдагы курчаклар һәм йомшак уенчыклар, төсле туплар;
8. Мәгълүмәти-информацион сылтамалар:
ГУП РТ «Татарское книжное издательство» – https://tatkniga.ru/library;
ООО «Издательство Магариф-Вакыт» – https://magarif-vakyt.ru/new4;

ООО «Татармультфильм» – http://publishertm.ru/электронная-форма-учебника/;
ГНБУ «Академия наук Республики Татарстан»
http://www.antat.ru/ru/iyli/publishing/book/;
ГАОУ ДПО «Институт развития образования Республики Татарстан»
http://www.irort.ru/node/3638.

# IV БҮЛЕК
## 15. Программаны үзләштерү сыйфатын билгеләү

# 16. Кулланылган әдәбият

1. Закирова К.В., Гаффарова С.М. “Әткәм-әнкәмнең теле”, Казан “Мәгариф, 1997.
2. Гарәфиева Г.З. “Сөмбеләне кем белә?” Казан “Тарих” 2003.
3. Ягъфаров Р.А. “Татар балалар фольклоры” Казан “Раннур” 1999.
4.Харрасова Р.Ф. “Бармакларны уйнатыйк, туган телне өйрәник” Казан “Хәтер” 1997.
5. Балалар өчен хрестоматияләр: “Гөлбакча”, “Раушан көзге”, “Балачак аланы” Казан: РИЦ, 2011.
6. Закирова К.В. “Әй уйныйбыз, уйныйбыз...” Казан, 2013.
7. Закирова К.В., Кадыйрова Р.Ә., Сафиуллина Г.М. “Балалар бакчасында әдәп-әхлак тәрбиясе” Казан, 2013.
8. Журналлар: “Мәгариф”, “Күчтәнәч”, “Салават күпере”, “Тылсымлы куллар”
9. Балаларга үгет-нәсыйхәт. – Казан: “Дом печати” нәшрияты. – 2001.
10. Р. Фәхретдин. Гаилә. Тәрбияле хатын. Балаларга нәсыйхәт. Төзүче – мөхәррир Ә. Хәйри. Казан, 2006.
11. Р. Фәхретдин. Тормыш юлы. Иҗади мирасы. Төзүче – Шаһиев Р. Казан, 2005.